РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» февраль 2010 ел г. Альметьевск № 255

Әлмәт муниципаль районында
җирле әһәмияттәге гомуми
файдаланудагы автомобиль
юлларында авыр йөк ташучы
транспорт чаралары китерә
торган зыян күләмен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» 2009 елның 3 сентябрендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 сентябрендәге 699 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләргә (1 нче кушымта).

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен билгеләү турында» 2011 елның 24 июнендәге 2482 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

Зак. № 305-2000

1 нче кушымта
Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының
«25» февраля 2020 ел № 235
карары белән расланды

Әлмәт муниципаль районында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләме
КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕ

Рөхсәт ителгән массаның иң чик күрсәткеченнән артып киткән очракта авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыян күләме

1 нче таблица

| № п/п | Транспорт чарасының рөхсәт ителгән иң чик массасын арттыру (процентларда) | Зыян күләме (сум 100 км) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | 10га кадәр | 2850 |
| 2 | 10нан 20гә кадәр | 3260 |
| 3 | 20дән 30га кадәр | 3668 |
| 4 | 30дан 40ка кадәр | 4078 |
| 5 | 40тан 50гә кадәр | 4486 |
| 6 | 50дән 60ка кадәр | 4896 |
| 7 | 60тан артык | Транспорт чаралары китерә торган зыян күләме, рөхсәт ителгән масса зурлыклары 60% тан арткан очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташый торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 сентябрендәге 699 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен исәпләү» дигән формула буенча исәпләнә. |

Иң чик мөмкин булган күчәр йөкләнешләренең күрсәткечләрен арттырганда авыр йөк ташучы транспорт чаралары китерә торган зыянның күләме

2 нче таблица

| № п/п | Транспорт чарасы күчәренә иң чик рөхсәт ителгән күчәр йөкләнешләрен арттыру ( процентларда) | Зыян күләме, 100 км га сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Рөхсәт ителгән күчәр йөкләнешләре 6 т/ күчәр | Рөхсәт ителгән күчәр йөкләнешләре 10 т/ күчәр | Рөхсәт ителгән күчәр йөкләнешләре 11,5 т/ күчәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | 10га кадәр | 5002 | 1288 | 550 |
| 2 | 10нан 20гә кадәр | 5925 | 2059 | 797 |
| 3 | 20дән 30га кадәр | 7403 | 3294 | 1193 |
| 4 | 30дан 40ка кадәр | 9419 | 4978 | 1732 |
| 5 | 40тан 50гә кадәр | 11959 | 7099 | 2411 |
| 6 | 50дән 60ка кадәр | 15013 | 9651 | 3228 |
| 7 | 60тан артык | Транспорт чаралары китерә торган зыянның күләме, рөхсәт ителә торган күчәр йөкләнешенең күрсәткечләрен 60%тан артыкка арттырганда, барлык норматив күчәр йөкләнешләре (6, 10, 11.5 тонна/күчәр) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының региональ һәм муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөк ташый торган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 сентябрендәге 699 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйлап авыр йөкләр ташуны гамәлгә ашыручы транспорт чаралары китерә торган зыян күләмен исәпләү» дигән формула буенча исәпләнә. | | |

Район Башкарма комитеты
җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косарев